ПРОЕКТ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «__» сентябреннән № ____

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районының спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бәяләрне раслау турында» 2025 елның 23 гыйнварындагы 16 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле һәм керем китерә торган башка хезмәтләр күрсәтү турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2023 елның 29 декабрендәге 40-325 номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтүне тәртипкә салу максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районының спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бәяләрне раслау турында» 2025 елның 23 гыйнварындагы 16 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бәяләр прейскуранты дигән таблицаны түбәндәге эчтәлектәге 27, 28 пунктлар белән тулыландырырга:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| « 27 | Ял иту бүлмәсендә яшәү 1 ятак-урын (тәүлек) | 1 кеше | 600,00 | - | |
| 28 | «Олимп» универсаль спорт залында комплекста хезмәтләр күрсәтү | 2 сәгать | 2500,00 | - | ». |

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: http:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Фасахов